БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«30» 04 2021 ел № 166

Торак урыны мәйданының хисап нормасы һәм социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны мәйданын бирү нормасы турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 50,58 статьяларын гамәлгә ашыру, дәүләт торак программаларын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәпкә алу максатларында аларны торак урыннарның гомуми мәйданы белән тәэмин итү дәрәҗәсен билгели торган торак урыны мәйданының хисап нормасын гаиләнең бер әгъзасына торак урынның гомуми мәйданын 18 кв.метрдан артмаган күләмдә билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннары белән тәэмин ителешнең ирешелгән дәрәҗәсеннән чыгып, социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны мәйданын бирү нормасын бер гражданга торак урынның гомуми мәйданын 18 кв. метр итеп билгеләргә.
3. Торак урынының гомуми мәйданын бирү нормасын арттыру Россия Федерациясе Торак кодексында каралган очракларда рөхсәт ителә.
4. «Балтаҗ муниципаль районында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарга торак урыны бирү нормасы һәм мәйданның хисап нормасы турында» 2020 елның 6 мартындагы 115 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.
5. Әлеге карарны pravo.tatarstan.ru «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырырга һәм baltasi.tatarstan.ru Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче А. Ф. Хәйретдинов